# ТУЙ ҖЫРЫ

*ШАМИЛ КАШАПОВ музыкасы*
*САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА сүзләре*

Ай-кояш йөзләре,
Кояшлы күзләре...
Кавышкан, табышкан
Пар былбыл үзләре.

*Кушымта:*
Карлыгачкаем ла,
Сандугачкаем ла;
Сайратыр, ай, матур
Яр булгач янында.

Талчыбык билләре,
Бал кебек телләре;
Гөрләшкән, серләшкән
Пар былбыл үзләре.

*Кушымта:*
Әйдер генәем,
Бәйдер генәем,
Юл булмый, туй булмый
Теләкләр теләми.

Бер генә дигәне —
Юктыр ла тиңнәре...
Уң, булсын, гел булсын
Бәхетле көннәре.